УРТА КУМОР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

20 ноябрь 2024 ел №35

«Җир салымы турында» 2023 елның 31 октябрьындагы 29 номерлы Урта Кумор авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Урта Кумор авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2023 елның 31 окябрьындагы 29 номерлы Урта Кумор авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.2 пунктчасында «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1.3 пунктчасында «һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә»;

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә 1 ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы С.В.Федоров